Бәхет кошы — яңа ел, канатланып үз түрдән!

Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!

САБАНТУЙ

БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ГАЗЕТАСЫ

● № 104 (4510) ● 29 декабрь, 1993 ел. ●

Кышкы нәкыш.

Саша ЯВГАРЕЕВ фоторәсеме.
Чистай. 18 нче мәктәп.

Тәрәзәгә карале
Нинди матур бизәкләр.
Кыш бабай ясаган аны
Сырлап-сырлап чәчәкләп.

Тышта шундый суык бит?!
Ничек алар туңмыйлар?
Әллә алар тун кигән?
Кыш бабай салып биргән.

Гөлназ ХӘСӘНОВА.
Арча. Югары Оры.

Наташа ЛЕДНЕВА рәсеме.
Казан, 13 яшь.

БЕЛМИМ, сезгә ничектер, минем үземә Җир шары гадәттәгедән тизрәк әйләнә башлады шикелле. Күз ачып йомарга өлгермисең, еллар үтә дә китә, үтә дә китә. Чираттагы өтәч елы да койрыгын гына күрсәтеп калды. Әллә ниләр эшләрбез дип өтәчләнгән идек тә, ул кадәр булдырып булмады әле. Алай да елны бушка уздырмадык үзе. Малайлар, кызлар тагын бер яшькә үсте, без үзебез тагын бер яшькә олыгайдык. Әти-әниләребез, әби-бабаларыбыз бер яшькә картайдылар. Суверен Татарстаныбызга өч яшь тулды. Дәүләт Гимныбыз туды. Балаларның сәнгать фестивале булды...

Урам тулы чит ил машиналары. Кибетләрнең киштәләре чит ил әйберләреннән, чит ил ризыкларыннан сыгылып тора. Өсләребездә импортный чүпрәк-чапрак. Бик теләсәң, урам буйлап авыз тутырып «Сникерс», «Марс» ашап йөрергә мөмкин. Телевизордагы кебек. Бик теләсәң матур савытлы «Кока-кола», «Пепси-кола», «Фанта» кебек әллә нинди тәмле сулар эчәргә була. Кибетләр, киосклар тулы алар. Чит ил балалары гына эчкәндә түгел. Акча да бер букча бездә. Ленин бабай башы төшкән акчаларның кадере бар иде, ике башлы бөркет төшерелгәннәрнең бәясе бөтенләй юк. Мең сумлыкларны без элек төштә дә күрми идек. Хәзер әнә бер шоколад та 1000 сум тора, ачуым да бер килмәгәе!..

Ә менә сәясәткә килгәндә, эшләребез тагын да авыррак, катлаулырак, четереклерәк, хәвефлерәк һәм, әлбәттә инде, шау-шулырак. Олы йортта ни булса, кече йортта шул булыр, дигәндәй, Рәсәйдәге хәлләр безгә дә тәэсир итми калмый. Анда исә талашалар, сугышалар, бер-берсен утка тоталар. Кыскасы, чын-чынлап революцияле уйныйлар. Рәсәй парламентын атып тараттылар. Монысы әйбәт түгел, безгә шәп парламент кирәк дигәннәр иде, әлеге сайлауларда Дәүләт Думасына да, Федераль Советка да элекке депутатлар, элекке коммунистлар, шовинистлар һәм яңа фашистлар кереп тулды. Жириновский үзе генә дә ни тора! Әлбәттә, демократлар да бераз бар араларында... Аларның демократлыкларын әйтер идем инде. Берсеннән дә өмет юк. Барысы да шул бер чыбыктан куылган.

Безнең Татарстанда хәлләр ярыйсы әле. Ачтан үлмәскә тырышабыз, һәр кешене социаль яктан якларга, иминлекне сакларга омтылабыз. Халыкларыбыз шөкер, үзара тату яшиләр. Рәсәй сайлауларында катнашмавыбыз, Рәсәй конституциясен кабул итмәвебе шулай ук куанычлы вакыйга. Димәк, суверенлыкны күбебез яклый дигән сүз...

Эт елына кереп барабыз. 1994 ел безне өреп каршы ала. Һау-һаулап Яңа ел килә. Маэмай елыннан да әйбәт ел булмас әле, аллаһы бирсә, менә күрерсез. Эт көнендә калмабыз, этләшмичә генә, тешләшмичә генә, шыңшымыйча гына яшәрбез дип уйлыйм. Әнә, ишетәсезме, Иске ел белән Яңа ел очраша:

— Кик-ри-кү-ү-үк!
— Һау-һау, һау-һау!

Роберт абыегыз МИҢНУЛЛИН.

БЕЗНЕ ДӨНЬЯ ТАНЫЙ

Минем туган авылым Иске Йөрек Киров өлкәсенең Малмыж районына карый.

Мин дә башка малайлар кебек яшел чирәмдә аунап, өйдә әти-әнигә булышып үстем. Югары классларда укыганда гер күтәрү белән мавыгып киттем. Бу гадәтемне армия сафларында хезмәт иткәндә дә, аннан кайтып Нократ Аланы бистәсендә эшләгәндә дә дәвам иттем. Хәзер хатыным Диләнең туган җире Кукмарада яшибез.

1993 ел минем өчен бик тә бәхетле ел булды. Яз көне атаклы баһадир Николай Жеребцов истәлегенә үткән бәйгедә бүләк алдым. Җәй бетеп килгәндә Казанның Үзәк стадионында — халыкара кичке сабантуйда баш батыр булып танылдым. Аннан соң Рәсәй беренчелегендә дүртенче урынны яуладым. Липецкида үтәчәк беренче дөнья чемпионатына аеруча нык әзерләндем. Татарстан герчеләренең аерым команда булып чыгыш ясаулары да шактый көч өстәде. 90 килограммлы үлчәүдә без гер күтәрү күперчегенә үнөчәү чыктык. Арада Казахстан, Украина, Литва, Үзбәкстан кебек дәүләтләрдән бик көчле спортчылар бар иде. Ике потлы ике герне этәреп күтәрү (толчок) алымында мин 131 очко җыйдым һәм алга чыктым. Ә инде берәр герне ике кул белән дә аерым-аерым (рывок) баш очына 98 әр тапкыр чөйдем. Димәк, мин — чемпион. Дөнья чемпионы!

Шушы җиңү хөрмәтенә җөмһүриятебез әләме күтәрелеп, үз Гимныбыз яңгыраганда минем генә түгел, командадашларым Җәмил Шакиров, Иван Стекольников, Мәдәррис Бикушев, баш тренерыбыз Әсгать Шәйхетдинович Шәйхетдиновның да күзләрендә яшь бөртекләре ялтырый иде.

Ниһаять, спорт дөньясында да безнең мөстәкыйльлегебезне таный башладылар.

Быелгы ел тагын нәрсәсе белән истә калды дисезме? Дөнья чемпионы булып кайткач, Кукмара район администрациясе безнең гаиләгә ике бүлмәле фатир бирде. Бу хәлгә үзебез дә, кызыбыз да, аның әбибабайлары да бик шатланды.



Фәнис СӘЛӘХИЕВ,
гер күтәрү буенча дөнья чемпионы.
Н. КУРАМШИН фоторәсеме.

Котлы яңа

	Январь	Февраль	Март	Апрель	Май	Июнь
Д	3 10 17 24 31	7 14 21 28	7 14 21 28	4 11 18 25	2 9 16 23 30	6 13 20 27
С	4 11 18 25	1 8 15 22	1 8 15 22 29	5 12 19 26	3 10 17 24 31	7 14 21 28
Ч	5 12 19 26	2 9 16 23	2 9 16 23 30	6 13 20 27	4 11 18 25	1 8 15 22 29
П	6 13 20 27	3 10 17 24	3 10 17 24 31	7 14 21 28	5 12 19 26	2 9 16 23 30
Ж	7 14 21 28	4 11 18 25	4 11 18 25	1 8 15 22 29	6 13 20 27	3 10 17 24
Ш	1 8 15 22 29	5 12 19 26	5 12 19 26	2 9 16 23 30	7 14 21 28	4 11 18 25
Я	2 9 16 23 30	6 13 20 27	6 13 20 27	3 10 17 24	1 8 15 22 29	5 12 19 26

ДӨНЬЯДА бу бәйрәмне бик күптәннән бәйрәм итәләр инде. Яңа ел килүенә һәрбер кеше сөенә. Ләкин һәркем аны үзенчә каршы ала. Үзенчә бәйрәм итә.

ЯШЕЛ чыршы алып кайтып, аны бизәү гадәте XVII гасырда беренче тапкыр Германиядә барлыкка килгән. Ә моңа чаклы бары тик ылыслы агачларның ботакларын гына бизи торган булалар.

ГЕРМАНИЯДӘ беренче тапкыр чыршы бизәгәндә, Россия Яңа ел бәйрәмен 1 сентябрь көнне билгеләп үткән. Бу көнне монда зур тантана булган. Кремльнең киң мәйданында патша үз тәхетендә утырган. Аның тирәсендә боярлар тезелеп басканнар. Шунда ук Патриарх җыелган халыкны Яңа ел белән котлап изге су бөркегән.

1700 нче елның 1 гыйнварында гына, Петр I патшаның махсус әмере белән Яңа ел бәйрәме Россиядә кышкы бәйрәмгә әйләнгән. Халык беренче тапкыр өйләрен нарат, чыршы ботаклары белән бизәгән. Мәскәүдә пушка һәм мушкетлардән атканнар. Мәйданнарда зур учаклар якканнар, аллыгөлле фейерверклар яндырганнар.

ИНДОНЕЗИЯДӘ Яңа елны октябрь аенда бәйрәм итәләр. Кешеләр иң матур киемнәрен киялер, күңел ачалар. Узган елда булган күңелсез хәлләр өчен бер-берсеннән гафу үтенәләр.

БИРМАДА Яңа ел апрель аенда башлана. Бу андагы иң эссе көннәргә туры килә. Атна буена бирмалылар бер-берсен су белән коендыралар. Бу су фестивале — тинджан дип атала.

КОРЕЯДА һәр гаилә Яңа елга яңа киемнәр тегә. Иске киемнәр белән узган елгы кайгы-хәсрәтләр дә, авырулар да китә дип саныйлар анда.

АВСТРАЛИЯДӘ Яңа ел 1 гыйнвар көнне башлана. Анда бу вакытта иң кызу көннәр була. Шуңа күрә Кыш бабай белән Кар кызы бүләкләрне йөзү киемнәре киеп таратып йөриләр.

ЯҢА ЕЛНЫ бәйрәм итү өчен берәүләр 1 апрельне көтә, икенчеләр — октябрьне, өченчеләр — гыйнварны. Ә эскимос халкы беренче кар төшкәнне өзелеп көтә. Беренче кар төшүгә, алар Яңа ел бәйрәмен уздыра башлыйлар.

ҺИНДСТАНДА Яңа ел итеп билгеләп үтә торган сигез бәйрәм бар. Шундый бер көн, мәсәлән, Гуди Падва дип йөртелә. Бу көнне ним-ним агачының яфракларын авыз итү мәҗбүри. Бигрәк тәмсез, ачы инде бу яфраклар! Борынгы ышанулар буенча бу үсемлек кешене авырудан, кайгы-хәсрәттән саклый. Яңа елда аны авыз иткән кешегә ул рәхәт, татлы тормыш алып килә икән.

КЫТАЙДА Яңа елны хлопушкалар, ракеталар шартлатып бәйрәм итәләр. Элек шартлаткычлар урынына бамбук агачын кулланганнар. Аның кайрысы янганда бик каты шартлый икән. Кытайда тагын бер шәп гадәт бар. Яңа елның беренче көннәрендә сүгенү, үзара кычкырышу катгый тыела.

ӘГӘР сезгә Яңа ел алдыннан Италиядә булырга туры килсә, зинһар өчен, йортларның стеналарына якын килмәгез. Италиялеләрнең Яңа елга каршы төндә тәрәзәдән искемоскы әйберләрне ата торган әкәмәт кызык гадәтләре бар. Ул көнне тәрәзәдән урамга ватык гөл чүлмәге дә, урындык та, тишек итек тә, барысы да оча... Бервакыт шулай хәтта зур борынгы шкафны тәрәзәдән җибәргәннәр... Никадәр күбрәк әйбер ташласаң, Яңа елда шулкадәр күп байлык килә, дип ышана ерак Италия халкы.